| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 6 сентябрь № 615

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенция ратификацияләнү белән бәйле инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче, 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы китапханәләреннән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

унөченче, уналтынчы абзацларны төшереп калдырырга;

VII бүлекнең 7.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Инвалид булган дәүләт хезмәтен алучылар (кресло-коляска һәм озатучы этләрдән файдаланучыларны да кертеп) түбәндәгеләр белән тәэмин ителергә тиеш:

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга каршылыксыз керү өчен шартлар;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук аларга керә һәм чыга алу мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү функцияләре озак бетми торган инвалидларны озата бару өчен шартлар;

инвалидларның хезмәт күрсәтелә торган объектларга һәм, аларның яшәү эшчәнлеге чикле булуын исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керә алуны тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү җайланмаларын тиешенчә урнаштыру өчен шартлар;

инвалидлар өчен зарур тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язулар, билгеләр һәм Брайлның рельеф-нокта шрифты билгеләре белән башкарылган бүтән текст һәм график мәгълүматны сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчедән файдаланып кабатлау;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга тиешле документы булган озата баручы этне кертү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бер тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуга комачаулый торган киртәләрне үтүдә халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.»;

Х бүлекнең 10.1 пунктындагы икенче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, бүтән юридик затлар күрсәтә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре, бүтән юридик затлар күрсәтә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлегеннән» сүзләрен «китапханәне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы раслаган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләре ведомство исемлегеннән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 8 июль, 467 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 29 сентябрь, 721 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

унөченче, уналтынчы абзацларны төшереп калдырырга;

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.5 пункт өстәргә:

«7.5. Инвалид булган дәүләт хезмәтен алучылар (кресло-коляска һәм озатучы этләрдән файдаланучыларны да кертеп) түбәндәгеләр белән тәэмин ителергә тиеш:

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга каршылыксыз керү өчен шартлар;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук аларга керә һәм чыга алу мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү функцияләре озак бетми торган бозылган инвалидларны озата бару өчен шартлар;

инвалидларның хезмәт күрсәтелә торган объектларга һәм, аларның яшәү эшчәнлеге чикле булуын исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керә алуны тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү җайланмаларын тиешенчә урнаштыру өчен шартлар;

инвалидлар өчен зарур тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язулар, билгеләр һәм Брайлның рельеф-нокта шрифты билгеләре белән башкарылган бүтән текст һәм график мәгълүматны сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчедән файдаланып кабатлау;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга тиешле документы булган озата баручы этне кертү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бер тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуга комачаулый торган киртәләрне үтүдә халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.»;

11 бүлекнең 5 графасында:

1 һәм 2 пунктларда «№ к-2рик «Киноҗайланмалар булу һәм аларны эксплуатацияләү» федераль дәүләт статистика күзәтүе» формасы» сүзләрен «Тармак хисаплылык формасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «№ 10-нк «Кино күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешма эше турында мәгълүматлар» формасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 август, 562 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 август, 593 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Спектакльләр, концертлар һәм концерт программалары, цирк номерлары һәм программалары, башка тамаша программалары оештыру, кую һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

ундүртенче һәм егерме икенче абзацларны төшереп калдырырга;

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.5 пункт өстәргә:

«7.5. Инвалид булган дәүләт хезмәтен алучылар (кресло-коляска һәм озатучы этләрдән файдаланучыларны да кертеп) түбәндәгеләр белән тәэмин ителергә тиеш:

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга каршылыксыз керү өчен шартлар;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук аларга керә һәм чыга алу мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү функцияләре озак бетми торган бозылган инвалидларны озата бару өчен шартлар;

инвалидларның хезмәт күрсәтелә торган объектларга һәм, аларның яшәү эшчәнлеге чикле булуын исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керә алуны тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү җайланмаларын тиешенчә урнаштыру өчен шартлар;

инвалидлар өчен зарур тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язулар, билгеләр һәм Брайлның рельеф-нокта шрифты билгеләре белән башкарылган бүтән текст һәм график мәгълүматны сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчедән файдаланып кабатлау;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга тиешле документы булган озата баручы этне кертү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бер тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуга комачаулый торган киртәләрне үтүдә халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.»;

10 бүлекнең 10.1 пунктындагы алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, бүтән юридик затлар күрсәтә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре, бүтән юридик затлар күрсәтә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлегеннән» сүзләрен «китапханәне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы раслаган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләре ведомство исемлегеннән» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды предметларын бастырып чыгару буенча (халыкка күрсәтү, басмаларда күчереп ясау, чыганакларның электрон һәм башка төрләрендә, шул исәптән виртуаль режимда) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды предметларын бастырып чыгару буенча (халыкка күрсәтү, басмаларда күчереп ясау, чыганакларның электрон һәм башка төрләрендә, шул исәптән виртуаль режимда) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

унҗиденче, унтугызынчы абзацларны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле егерме дүртенче абзац өстәргә:

«Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенә федераль статистика күзәтүен оештыру өчен статистика инструментларын раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 671 нче боерыгы»;

6 бүлекнең 6.3 пунктындагы өченче абзацта «1994 елның 2 декабре» сүзләрен «1994 елның 21 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.7 пункт өстәргә:

«7.7. Инвалид булган дәүләт хезмәтен алучылар (кресло-коляска һәм озатучы этләрдән файдаланучыларны да кертеп) түбәндәгеләр белән тәэмин ителергә тиеш:

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга каршылыксыз керү өчен шартлар;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук аларга керә һәм чыга алу мөмкинлеге;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәтләнү функцияләре озак бетми торган бозылган инвалидларны озата бару өчен шартлар;

инвалидларның хезмәт күрсәтелә торган объектларга һәм, аларның яшәү эшчәнлеге чикле булуын исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керә алуны тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү җайланмаларын тиешенчә урнаштыру өчен шартлар;

инвалидлар өчен зарур тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язулар, билгеләр һәм Брайлның рельеф-нокта шрифты билгеләре белән башкарылган бүтән текст һәм график мәгълүматны сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчедән файдаланып кабатлау;

хезмәтләр күрсәтелә торган объектларга тиешле документы булган озата баручы этне кертү мөмкинлеге;

инвалидларга башка затлар белән бер тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуга комачаулый торган киртәләрне үтүдә халыкка хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков